ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СУЫКСУ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422729, Татарстан Республикасы, Биектау районы,
Суыксу авылы, Мәктәп ур., 9А

СОВЕТ СУКСИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422729, Республика Татарстан, Высокогорский район,
с. Суксу, ул. Школьная, 9А

Тел./факс: +7(84365) 61-8-43, e-mail: Suks.Vsg@tatar.ru

**КАРАР** **РЕШЕНИЕ**

**26 август 2020 ел** **№ 194**

**Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итү Тәртибе турында**

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында», 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы «Коррупциягә каршы көрәш турында» Федераль законнар, 2017 елның 19 июлендәге 56-ТРЗ номерлы «Контракт буенча муниципаль вазыйфа яки җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, контракт буенча муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт турында һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр хакында белешмәләр тапшыру тәртибе турында», 2017 елның 19 июлендәге 57-ТРЗ номерлы «Контракт буенча муниципаль вазыйфа яки җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүне дәгъвалаучы гражданнар, контракт буенча муниципаль вазыйфаларны яисә җирле администрация башлыгы вазыйфасын биләүче затлар тапшырган белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү турында» Татарстан Республикасы законнары, «Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Суыксу авыл җирлеге Советы,

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Түбәндә китерелгән «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итү Тәртибен расларга.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең рәсми стендларында, Биектау муниципаль районы рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ авыл җирлекләре бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карар аның рәсми басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеге Башлыгы Р.С.Низамиев

Кушымта
Расланды
Татарстан Республикасы Биектау
муниципаль районы Суыксу авыл
җирлеге Советының 2020 елның
26 августы № 194 карары белән

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итү Тәртибе**

1. Әлеге Тәртип «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге» депутатына, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасына, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затына (алга таба - муниципаль вазыйфа биләүче зат) карата үз керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр (алга таба - керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр) биргән өчен, әгәр бу белешмәләрне бозу җитди булмаса, җаваплылык чаралары күрү турында карар кабул итү процедурасын регламентлый.

2. 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясындагы 7.3-1 өлеше нигезендә керемнәре, чыгымнары, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр биргән муниципаль вазыйфалар биләүче затларга карата түбәндәге җаваплылык чаралары кулланыла:

1) кисәтү;

2) муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең депутатын, башка сайлаулы органы әгъзасын Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советында, муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең башка сайланулы органында вазыйфасыннан, аның вәкаләтләре чоры тәмамланганчыга кадәр, Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советында, муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең башка сайланулы органы вазыйфасын биләү хокукыннан мәхрүм итеп азат итү;

3) вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыру хокукыннан мәхрүм итеп, даими нигездә вәкаләтләрне гамәлгә ашырудан азат итү;

4) Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советында, муниципаль берәмлекнең башка җирле үзидарә сайлау органында аның вәкаләтләре вакыты беткәнче вазифа биләүне тыю;

5) вәкаләтләре чоры туктатылганчы даими нигездә вәкаләтләр башкаруны тыю.

3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга карата әлеге Тәртипнең 2 пунктында санап үтелгән җаваплылыкның бер чарасын куллану мәсьәләсе Биектау муниципаль районының Суыксу авыл җирлеге Советында карала (алга таба – Совет).

Күрсәтелгән мәсьәләне карау өчен нигез булып Советка 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 40 статьясындагы 7.3 өлешендә каралган Татарстан Республикасы Президентының муниципаль вазыйфа биләүче затка карата җаваплылык чаралары күрү турындагы гаризасы керүе тора.

4. Җаваплылык чараларын куллану турында Татарстан Республикасы Президенты гаризасы кергәннән соң Совет тарафыннан өч айдан да соңга калмыйча карала.

5. Совет муниципаль вазыйфаны биләүче затка аңа карата җаваплылык чараларын куллану турындагы мәсьәләне карау турында күрсәтелгән мәсьәләне карау датасына кадәр кимендә биш эш көне кала язма рәвештә хәбәр итә.

Совет утырышының һәм утырыш вакыты турында хәбәр ителгән муниципаль вазыйфа биләүче затның килмәве җаваплылык чараларын куллану турындагы Татарстан Республикасы Президентының гаризасын карауга комачауламый.

6. Татарстан Республикасы Президентының муниципаль вазыйфа биләүче затка җаваплылык чараларын куллану турында гаризасы Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Суыксу авыл җирлеге Советы карары белән расланган Совет Регламентында билгеләнгән тәртиптә Совет утырышында карала (алга таба – Регламент).

Күрсәтелгән мәсьәләне караганда муниципаль вазыйфаны биләүче затка тапшырылган белешмәләр буенча аңлатмалар бирү мөмкинлеге бирелергә тиеш.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затка карата куллану мәсьәләсе каралганда, депутатларның җаваплылык чараларының берсе мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау һәм җайга салу буенча таләпләр үтәлергә тиеш. Совет утырышында рәис депутатларга мәнфәгатьләр конфликты барлыкка килү мөмкинлеге турында хәбәр итәргә тәкъдим итәргә тиеш.

Мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яисә җайга салу максатларында мәнфәгатьләр конфликты ягы булган депутат, карар кабул итүдән рәислек итүче тарафыннан читләштерелә.

7. Татарстан Республикасы Президенты гаризасын карау нәтиҗәләре буенча муниципаль вазыйфаны биләүче затка җаваплылык чараларын куллану турында яки җаваплылык чараларын кулланудан баш тарту турында карар кабул ителә.

Күрсәтелгән карар Регламентта билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

Аңа карата Татарстан Республикасы Президенты гаризасы кергән депутат тавыш бирүдә катнашмый.

8. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карар гаделлек, күләменә туры килү, пропорциональлек һәм котылгысызлык принциплары нигезендә, кылынган коррупциячел хокук бозу характерын, аның авырлыгын, шулай ук муниципаль вазыйфа, үз вазыйфаи бурычларын (вәкаләтләрен) биләгән зат тарафыннан башкарылган элеккеге нәтиҗәләрен исәпкә алып, коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән башка чикләүләрне, тыюларны һәм бурычларны үтәве нигезендә кабул ителә.

Хисап чорында керемнәр турында, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшырган өчен бары тик бер җаваплылык чарасы гына кулланылырга мөмкин.

9. Җаваплылык чарасын куллану турындагы карарда коррупцион хокук бозуга күрсәтмә, муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан бозылган норматив хокукый актлар нигезләмәләре, карарга карата Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерү хокукы булырга тиеш.

10. Җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарда мондый баш тартуның дәлилләнгән нигезләмәсе булырга тиеш.

11. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карарның күчермәләре кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә муниципаль вазыйфа биләүче затка имза куйдырып тапшырыла яисә тапшыру турында хәбәр белән почта аша җибәрелә, шулай ук Татарстан Республикасы Президентына җибәрелә.

Җаваплылык чарасын куллану турында карарны муниципаль вазыйфаны биләүче затка җиткерү мөмкин булмаса яки күрсәтелгән зат карарны имза куеп кабул итүдән баш тартса, коррупцион һәм башка хокук бозуларны профилактикалау өчен җаваплы зат тарафыннан күрсәтелгән затның җаваплылык чарасын куллану турындагы карар белән танышудан баш тартуы яисә аңа бу карар турында хәбәр итү мөмкинлеге булмау турында акт төзелә.

12. Җаваплылык чарасын куллану яисә җаваплылык чарасын кулланудан баш тарту турындагы карар Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять ителергә мөмкин.